СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «3» октябрь 2018 ел** **№ 6**

**«Яңа Чишмә авыл җирлеге башлыгы тарафыннан 2018 елның 20 апрелендә кабул ителгән 3 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы «Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 ноябрендә кабул ителгән 335 нче номерлы Федераль канун нигезендә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турындагы 3 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 пунктта «кануннар белән билгеләнгән вакыт» сүзләрен «кергәннән соң өч календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга
- 8 пунктта «кануннар белән билгеләнгән вакыт» сүзләрен «теркәлгәннән соң җиде календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга
- 12 пунктны яңа редакциядә уку «Гражданнарның мөрәҗәгате җирле үзидарә органнарында мөрәҗәгать язма рәвештә теркәлгәннән соң 30 көн эчендә карала.

Аерым очракларда, шулай ук сорау җибәргән очракта, мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документлар һәм материалларны судтан, сорау алу һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш, башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка вазыйфаи затларда карарга кирәк булганда, җитәкче яисә башлык, вазыйфаи зат яисә вәкаләтле зат мөрәҗәгатьне карау вакытын 30 көнгә озайтырга хокуклы.

- түбәндәге эчтәлекле 30 нчы пункт өстәргә:

«30. Аерым мөрәҗәгатьләрне карау тәртибе

1. Язма рәвештә мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап

җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр әлеге мөрәҗәгатьтә канунга каршы әзерләнә торган, кылыначак яки кылынган гамәлләр турында, шулай ук ул гамәләрне әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар бар икән, мөрәҗәгать аның компетенциясе белән бәйле дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

2. Суд карары өстеннән шикаять бирелгән мөрәҗәгать теркәлгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып кире кайтарыла.

3. Җитәкче, башлык яки вазыйфаи зат эчтәлегендә әдәпсез яисә мыскыллау сүзләре булган, аның тормышына, сәламәтлегенә һәм милкенә, шулай ук гаилә әгъзаларына куркыныч янаган язма мөрәҗәгать алган очракта, мөрәҗәгатьне анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм аны юллаган гражданга хокуктан явызларча файдалану ярамавы турында хәбәр итәргә хокуклы.

4. Язма мөрәҗәгать текстын укып булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул, аларның компетенциясенә нигезләнеп, дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка каралуга җибәрелә алмый, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгәннән соң җиде көн эчендә, фамилиясе һәм почта адресы укылган очракта, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр ителә.

4.1. Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул, аларның компетенциясенә нигезләнеп, дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка каралуга җибәрелә алмый, бу хакта мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн эчендә хәбәр ителә.

5. Гражданның язма мөрәҗәгатендә, элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләрендәге сорауларына берничә тапкыр язмача бирелгән җаваплар булуга карамастан, яңадан шул ук сорау бирелсә һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр яки шартлар күрсәтелмәсә, дәүләт органы яки җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат яисә вәкаләтле зат чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча граждан белән язуларны туктату турында Карар кабул итәргә хокуклы, әгәр дә күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булса. Әлеге карар мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

5.1. Җитәкчегә, авыл җирлеге башлыгына яисә вазыйфаи затка җавабы Федераль канунның 10 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә Яңа Чишмә авыл җирлеге рәсми сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган язма мөрәҗәгать кергән очракта, гражданга язма рәвештә мөрәҗәгате теркәлгәннән соң җиде көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына шикаять биргән мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап дәүләт яки Федераль закон тарафыннан саклана торган серне тәшкил итүче белешмәләрне

белдермичә бирелә алмый икән, мөрәҗәгать җибәргән гражданга, күрсәтелгән мәгълүматларны фаш итүгә юл куелмауга бәйле рәвештә, куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирергә мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

7. Нинди дә булса сәбәпләр аркасында мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирелмәгән һәм ул сәбәпләр соңрак бетерелгән очракта, граждан мөрәҗәгатен яңадан тиешле дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрергә хокуклы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan. ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Яңа Чишмә Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы В. М. Козлов